РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» февраль 2024 ел г. Альметьевск № 726

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2023 елның 5 декабрендәге 7582 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 10 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм муниципаль норматив актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2023 елның 5 декабрендәге 7582 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 пунктының алтынчы, җиденче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформаны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә куллану һәм социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада билгеләнгән форматларга ярашлы рәвештә социаль ярдәм күрсәтүнең әлеге чараларын күрсәтү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

Укучыларга социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформаны куллану һәм социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа форматына ярашлы рәвештә алырга мөмкин».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

заказ № 1-851

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов